**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«14» 03 2022 ел Яр Чаллы №25

Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегендә урнашкан 16:39:150301:862 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча халык тыңлауларын үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, Тукай муниципаль районы уставы, Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә (Тукай муниципаль районы Советының 2022 елның 9 декабрендәге 27/8 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән), Тукай муниципаль районының җирдән файдалану һәм авыл җирлекләре төзелешен алып бару кагыйдәләре проектларын әзерләү буенча ведомствоара комиссиясенең 2022 елның 12 декабрендәге карары нигезендә, Тукай муниципаль районы һәм Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге халкының уңайлы тормыш шартларына хокукларын, Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатыннан

**КАРАР БИРӘМ**

1. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегендә урнашкан 16:39:150301:862 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен «Торак иҗтимагый эшлекле объектларны урнаштыру һәм куллану өчен» төп төрдән «Шәхси торак төзелеше өчен» шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча халык тыңлауларын үткәререгә.

2.1. Әлеге карарны Тукай муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

2.2. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.

3. Халык тыңлауларын бер көндә, **2023 елның 26 апрелендә 14:30 сәгатьтә** үткәрергә, үткәрү урыны: Тукай муниципаль районы, Иске Дөреш авыл җирлеге, Иске Дөреш авылы, Г. Тукай ур., 21, авыл мәдәният йорты.

4. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы итеп О.А. Никитинаны билгеләргә.

5. Фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы Ф.М. Камаев

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2023 елның 14.03 23 номерлы карарына кушымта

Фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе

Әлеге тәртип җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатында эшләнгән һәм гражданнарының фикер алышуда катнашу, шулай ук халыкның фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның фикер алышуда катнашуы халык тыңлауларында катнашу һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына Тукай муниципаль районы халкы тарафыннан язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр **2023 елның 23 мартыннан 2023 елның 25 апреленә кадәр** түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Яр Чаллы ш., Муса Җәлил пр., 46, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 кабинет.

3. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.

4. Халык тыңлаулары секретаре фикерләр, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.

5. Халык тыңлаулары башланганчы, халык тыңлауларында катнашучылар секретарь тарафыннан теркәлә. Теркәү кәгазендә халык тыңлауларында катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны күрсәтелә.

6. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә: чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә; фикер алышу өчен – 3 минутка кадәр; фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.

7. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла. Беркетмәгә халык тыңлауларын оештыручы һәм секретарь имза куя.

8. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә: халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме; халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны; халык тыңлауларында катнашкан гражданнарының саны; халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

9. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм мәҗбүри рәвештә «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырылырга һәм Тукай муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.